КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 15 октябрь г.Казань № 929

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итү һәм аны оештыру чыгымнарын финанслау тәртибе турында» 2009 ел, 31 декабрь, 933 нче карары белән расланган Өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итү һәм аны оештыру чыгымнарын финанслау тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итү һәм аны оештыру чыгымнарын финанслау тәртибе турында» 2009 ел, 31 декабрь, 933 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 7 июнь, 438 нче; 2010 ел, 24 август, 676 нчы; 2010 ел, 22 декабрь, 1094 нче; 2011 ел, 25 гыйнвар, 41 нче; 2012 ел, 24 октябрь, 901 нче; 2013 ел, 28 март, 211 нче; 2016 ел, 26 август, 594 нче; 2017 ел, 13 июль, 492 нче; 2017 ел, 24 август, 597 нче; 2017 ел, 20 ноябрь, 892 нче, 2019 ел, 06 декабрь, 1121 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итү һәм аны оештыру чыгымнарын финанслау тәртибенә, түбәндәге эчтәлекле 9 абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

«баланың ата-анасы (законлы вәкиле) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында" 2004 ел, 17 декабрь, 542 нче карары белән билгеләнгән тәртиптә бирелә торган балага айлык пособие алучы булып торганлыкны раслый торган (гаиләнең җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән җан башына яшәү минимумы күләменнән артмый) «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе бүлекчәсе белешмәсе булу - ведомствоара соратып алулар юлы белән гаиләнең җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән җан башына яшәү минимумы күләменнән артмауны раслый торган мәгълүмат алу буенча ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне гамәлгә ашырганчыга кадәр, шул исәптән, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасын кулланып, электрон формада.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А. В. Песошин